| Республика Татарстан<br>Исполнительный комитет<br>Петровско-Заводского сельского<br>поселения Сармановского<br>муниципального района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районы<br>Петровский Завод<br>авыл җирлеге башкарма<br>комитеты |
|---|---|

| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |
|---|---|
| 2026 ел, 30 гыйнвар | № 1 |

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Петровский Завод авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2026 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» 2026 елның 23 гыйнварындагы 30 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. 2026 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча 9678,63 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2025 елның 30 гыйнварындагы 1 нче номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе — Р.Р.Нуртдинов

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге башкарма комитетынын 2026 елның 30 гыйнварындагы 1 номерлы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Петровский Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2026 елның 1 февраленнән үлгән кешенең күмү бурычын үз өстенә алган хатынына (иренә), якын туганнарына, башка туганнарына, законлы вәкилгә яисә башка затка җирләү эше буенча махсуслаштырылган хезмәт күрсәтә торган гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
| --- | --- |
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | – |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4 170,37 |
| 3.Мәетнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү | 1 913,26 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3 595,00 |
| Барлыгы | 9 678,63 |

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлеге
Башкарма комитетынын
2026 елның 30 гыйнварындагы
1 номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Петровский Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2026 елның 1 февраленнән үлгән кешенең хатыны (ире), якын туганнары, башка туганнары яки законлы вәкиле булмаган яки җирләү мөмкин булмаган очракта, шулай ук эчке эшләр органнары аның шәхесен билгеләгәннән соң,өйдә, урамда яки башка урында үлгән кешене җирләү бурычын үз өстенә алган башка кешеләр булмаганда, җирләү эше буенча махсуслаштырылган хезмәт күрсәтә торган гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе-(сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | – |
| 2. Кәфенләү | 1 500,00 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2670,37 |
| 3.Мәетнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү | 1 913,26 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3 595,00 |
| Барлыгы | 9 678,63 |